КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 24 февраль г.Казань № 111

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 май, 431 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 май, 431 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 311 нче; 2017 ел, 6 декабрь, 938 нче; 2019 ел, 21 сентябрь, 863 нче; 2020 ел, 3 август, 645 нче; 2021 ел, 20 сентябрь, 885 нче; 2022 ел, 29 март, 287 нче; 2022 ел, 13 август, 817 нче; 2023 ел, 10 февраль, 124 нче; 2023 ел, 18 март, 278 нче; 2023 ел, 6 ноябрь, 1424 нче; 2024 ел, 30 гыйнвар, 44 нче; 2024 ел, 6 апрель, 236 нчы; 2024 ел, 24 август, 692 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә:

«бер тапкыр финанс ярдәме» сүзләре алдына «эшсез гражданнарга» сүзләрен өстәргә;

«салым түләүче буларак» сүзләрен «түләүче буларак салым органында» сүзләренә алмаштырырга;

преамбулада «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы» сүзләрен «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 32 статьясындагы 3 өлеше, 37 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты, «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясындагы 3 өлешенең 1 пунктындагы икенче һәм уникенче абзацлары» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта:

«бер тапкыр финанс ярдәме» сүзләре алдына «эшсез гражданнарга» сүзләрен өстәргә;

«салым түләүче буларак» сүзләрен «түләүче буларак салым органында» сүзләренә алмаштырырга;

$1^1$ һәм $1^2$ пунктлар үз көчләрен югалткан дип танырга;

2 пунктта:

«бер тапкыр финанс ярдәме» сүзләре алдына «эшсез гражданнарга» сүзләрен өстәргә;

«салым түләүче буларак» сүзләрен «түләүче буларак салым органында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү тәртибендә:

исемендә:

«бер тапкыр финанс ярдәме» сүзләре алдына «эшсез гражданнарга» сүзләрен өстәргә;

«салым түләүче буларак» сүзләрен «түләүче буларак салым органында» сүзләренә алмаштырырга;

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 32 статьясындагы 3 өлеше, 37 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясындагы 3 өлешенең 1 пунктындагы икенче һәм уникенче абзацлары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда алар эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык итү максатларында эшсез гражданнарга Татарстан Респуб-

ликасы бюджеты акчасы исәбеннән бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү (алга таба – эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыру өчен бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү) күләмен һәм механизмын билгели.»;

1.2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Тәртипне гамәлгә ашыру өчен эшсез граждан дигәндә «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесендә (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәге) эшсез буларак теркәлгән Россия Федерациясе гражданы аңлашыла.»;

1.4 пунктта «эшсез гражданнарга» сүзләрен «эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыруга» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта «бер тапкыр финанс ярдәме» сүзләре алдына «эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыруга» сүзләрен өстәргә;

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.6 пункт өстәргә:

«1.6. Халыкны эш белән тәэмин үзәге Татарстан Республикасында эшсез гражданнар арасыннан инвалидларга эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру максатларында түбәндәге чараларны үткәрү турында мәгълүмат бирә:

инвалидларны эшмәкәрлек эшчәнлеге нигезләренә, финанс менеджментына, маркетингка һәм бизнес алып баруның хокукый аспектларына өйрәтүгә юнәлдерелгән, шул исәптән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасына керүче оешмаларны һәм учреждениеләрне (алга таба – «Минем бизнес») җәлеп итеп, махсуслаштырылган семинарлар һәм тренинглар уздыру;

базардагы үзгәрешләргә җайлашу һәм мәшгульлек статусын беркетү максатларында эшләүче эшмәкәрләр өчен махсуслаштырылган семинарлар һәм тренинглар (шул исәптән «Мой бизнес» оешмаларын җәлеп итеп) уздыру;

бизнесны теркәү, салым салу, бухгалтерлык исәбе, маркетинг һәм эшмәкәрлек эшчәнлегенең башка аспектлары мәсьәләләре буенча инвалидларга (шул исәптән «Мой бизнес» оешмаларын һәм башка оешмаларны җәлеп итеп) консультация хезмәтләре күрсәтү;

бизнесны булдыру һәм үстерүнең барлык этапларында һөнәри ярдәм күрсәтергә әзер консультантлар һәм экспертлар челтәрен булдыру, мондый челтәр турында инвалидларга мәгълүмат бирү;

инвалидлар өчен тәҗрибәле эшмәкәрләр остаз булачак менторлар программаларын үстерү. Менторлар киңәшләр бирергә, тәҗрибә белән уртаклашырга һәм үз эшләрен алып бару өлкәсендә таралган хаталарны ясамаска ярдәм итәргә мөмкин;

инвалидлар тарафыннан эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга, шул исәптән кайбер мәгълүмат ресурсларын булдыру яки булган интернет ресурсларда тиешле мәгълүмат урнаштыру, инвалидларның эшмәкәрәлек эшчәнлеге мөмкинлекләре һәм файдаланыла торган ресурслар турында хәбәрдарлыгын арттыруга юнәлдерелгән мәгълүмат кампанияләре уздыру өлешендә мәгълүмати ярдәм күрсәтү;

инвалидлар өчен эш урыннары булдыруга һәм саклауга ярдәм чараларын

гамәлгә ашыру өлешендә финанс ярдәме турында мәгълүмат бирү;

бизнес алып баруга бәйле стрессны һәм эмоциональ кыенлыкларны җиңү максатларында эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнүче инвалидларга психологик ярдәм күрсәтү һәм консультацияләр бирү өлешендә психологик ярдәм күрсәтү һәм мотивацияләү, инвалидларның ышанычын һәм мотивациясен арттыру максатларында волонтерлык, социаль башлангычларда профессиональ коучлар җәлеп итү, инвалидларның үз көчләренә ышанычын арттыруга һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген алып баруга мотивацияне арттыруга юнәлдерелгән мотивация программаларын һәм чараларын оештыру;

эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнүче инвалидлардан уңышлы тәҗрибәләрне һәм чишелеш таләп итә торган проблемаларны ачыкларга ярдәм итә торган кире элемтәне даими җыю.»;

II бүлекнең исеменә «Эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыру өчен» сүзләрен өстәргә;

2.1 пунктның беренче абзацында «үзәкләре» сүзен «үзәге» сүзенә алмаштырырга;

2.2 пунктта «бирелгән, эшсез гражданнарның эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча бәяләмә» сүзләрен төшереп калдырырга, «салым түләүче буларак» сүзләрен «түләүче буларак салым органында» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктта:

беренче абзацта «эшсез гражданнарның (билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органарының юлламасы буенча һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, һөнәри керемгә салым түләүче буларак физик затны исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне кертеп) эшмәкәрлек эшчәнлеген башлап җибәрүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында» һәм «(алга таба – гариза)» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «граждан эшсез буларак исәптә торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

сигезенче абзацта «үзәкләрендә» сүзен «үзәгендә» сүзенә алмаштырырга;

унберенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

2.8 пунктта:

өченче абзацта «гражданнарга шәхси эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алу, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алу, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алу, һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куелу өчен бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү турында яки гражданнарга шәхси эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алу, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алу, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алу, һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куелу өчен бар тапкыр финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында» сүзләрен «эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыру өчен бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «унберенче» сүзен «унынчы» сүзенә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «унберенче» сүзен «унынчы» сүзенә алмаштырырга;

2.9 пунктның өченче абзацында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2.12 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

2.13[1] пунктта:

беренче абзацта «салым түләүче буларак» сүзләрен «түләүче буларак салым органында» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «салым түләүче буларак» сүзләрен «түләүче буларак салым органында» сүзләренә алмаштырырга;

2.16 пунктта «гариза» сүзен төшереп калдырырга;

2.17 пунктта:

татар текстында җөмлә башына «эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыру өчен» сүзләрен өстәргә;

«салым түләүче буларак» сүзләрен «түләүче буларак салым органында» сүзләренә алмаштырырга;

2.18 пунктта татар текстында җөмлә башына «эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыру өчен» сүзләрен өстәргә;

3.1 пунктта «һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының юлламасы буенча һөнәри белем яки өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.2 һәм 3.3 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

3.4 пунктның беренче абзацында «үзәкләре» сүзен «үзәге» сүзенә алмаштырырга;

3.6 пунктының дүртенче абзацында «салым түләүче буларак» сүзләрен «түләүче буларак салым органында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипнең кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда эшсез гражданнарга бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 24 февраль, 111 нче
карары редакциясендә)

Форма

Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда эшсез гражданнарга бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү нәтиҗәсенә ирешү турында
хисап

| Нәтиҗәнең исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификациясе буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәнең план буенча күрсәткече | Хисап датасына карата нәтиҗәнең ирешелгән күрсәткече | Нәтиҗәнең план буенча күрсәткечен үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | исеме | коды | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алган, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алган, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алган, физик | ай | 366 | 12 | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйган көннән кимендә 12 ай эчендә бизнес-план нигезендә эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру | | | | | | |

________________________________ ____________________________________________________

(җитәкче вазыйфасы*) (җитәкче, шәхси эшмәкәр, һөнәри керемгә салым түләүче буларак салым органында исәпкә куелган физик зат имзасы, Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У.*

Баш бухгалтер* ____________ ______________________________________________
(имза) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

20___ ел, «___» __________

____________

*Булганда.

___________________________